| | |
|---|---|
| ЕЛАБУЖСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ<br>СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛАБУГА<br>ШӘҺӘР<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

19.05.2025 ел Алабуга шәһәре № 164

Татарстан Республикасы Алабуга шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципальара хезмәттәшлек оешмаларында катнашу тәртибе турында» 2011 елның 29 апрелендәге 46 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Алабуга шәһәр прокуратурасының протестын караганнан соң, Алабуга шәһәр Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Алабуга шәһәр Советының 2011 елның 29 апрелендәге 46 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципальара хезмәттәшлек оешмаларында катнашу тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Муниципальара хезмәттәшлек түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашырыла:

1) муниципаль берәмлекләр берләшмәләрендә муниципаль берәмлекләр әгъзалыгы;

2) муниципальара хуҗалык җәмгыятьләрен, муниципальара матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм челтәр басмасын оештыру;

3) муниципаль берәмлекләр тарафыннан коммерциягә карамаган оешмалар оештыру;

4) шартнамәләр һәм килешүләр төзү.

Алабуга шәһәр Советы җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне бергәләп хәл итү өчен гавами булмаган акционерлык җәмгыятьләре һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр рәвешендә муниципальара хуҗалык җәмгыятьләре оештыру турында карарлар кабул итә ала.

Муниципальара оешмалар коммерциягә карамаган автономияле оешмалар һәм фондлар рәвешендә төзелергә мөмкин.».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль төзелеш, хокук тәртибе һәм законлылык, шәһәр төзелеше, инфраструктура үсеше һәм торак-

коммуналь хуҗалыкны реформалаштыру мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Комиссия рәисе урынбасары К.В. Мокшин